**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

974-п от 19.11.2015

**Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Минзәлә елгасының су саклау зоналарын һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Су кодексының 26, 65 статьялары, 2007 елның 24 июлендәге “Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында” 221-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 10 гыйнварындагы “Җирлектә су объектларының сусаклагыч чикләрен һәм яр буе саклык полосаларын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында” 17 номерлы Карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 3 февралендәге “Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт күчемсез милек кадастрына белешмәләр кертү өчен зарури документларны күчемсез милеккә хокукларны һәм аңа карата алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу, кадастр исәбенә алу һәм күчемсез милекнең дәүләт кадастрын алып бару өлкәсендә вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына җибәрү кагыйдәләрен раслау турында, шулай ук мондый документларның электрон рәвештәге форматына карата таләпләр турында” 71 номерлы Карары, Россия Федерациясе Табигать министрлыгының 2010 елның 29 сентябрендәге “Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан федераль милектә булган һәм Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан су объектларын яки аларның өлешләрен саклау буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында” 425 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 6 июлендәге “Татарстан Республикасының Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы

мәсьәләләре” хакында 325 номерлы Карары, 2015 елның 27 мартындагы Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетына Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан 2015 елда су мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең аерым вәкаләтләрен башкаруга карата субвенцияләр бирү турында МТ-54/45 номерлы килешү һәм 2015 елның 16 июнендәге “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Минзәлә елгасы, Шомбыт елгасы, Әнҗерә елгасы, Чия елгасы, Бизнә елгасы, Шонталы елгасы, Олы Чирмешән (Чирмешән) елгасы, Иж елгасы, Туйма елгасы, Нократ елгасы, Ык елгасы, Сөлчә елгасы, Раифа күле су объектларының су саклау зоналарының һәм яр буе саклык полосаларының чикләрен билгеләү” темасы буенча 15 МЭ-4ф номерлы Дәүләт контракты кысаларында башкарылган эш нәтиҗәләре нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

1. 2006 елның 3 июнендәге № 74-ФЗ Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә, әлеге чикләрдә хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек башкаруның махсус тәртибен исәпкә алып, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Минзәлә елгасының су саклау зонасының һәм яр буе саклык полосасы киңлеген билгеләргә.

Минзәлә елгасының су саклау зонасы киңлеге – 200 м.

Минзәлә елгасының яр буе саклык полосасы киңлеге: яр 3 һәм аннан да күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр 3 градустан кимрәк авышлыклы булганда – 40 м; нульле яки кирегә таба авышлыкта – 30м.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (В.А. Тронин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә алам.

Министр в.б. Р.И. Камалов